ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР

№ _ 6_ Урыссу ш.т.п. "_24_" 04 2017 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәне раслау хакында**

2012 елның 24 гыйнварында Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының №1 карары белән кабул ителгән 2012 елның 24 гыйнварындагы «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы үз көченә керүгә бәйле рәвештә, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2006 елның 28 июнендәге 15 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендында игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы
- Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе Р.М. Нуриев

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Советының 24.04.2017 № 6
карары белән
расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең (алга таба - Җирлек) башкарма-боеру функцияләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы булып тора.
1.2. Башкарма комитет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларына, муниципаль районның норматив-хокукый актларына, Җирлек Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.
1.3. Җирлек Башкарма комитеты Җирлек Советына, Җирлек Башлыгына һәм Җирлектә яшәүчеләргә хисап тота һәм алар контролендә тора.
1.4. Башкарма комитет Җирлек территориясендә Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең территориаль органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән хезмәттәшлектә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

## 2. Юридик статус

2.1. Җирлек Башкарма комитетының рәсми исеме - «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты», кыскартылган исеме - Урыссу ш.т.п. Башкомы.
2.2. Башкарма комитетка юридик зат хокуклары бирелә.
2.3. Башкарма комитетның үз исеме язылган мөһер, штамплар, бланклар, Россия Федерациясе законнары нигезендә банк учреждениеләрендә исәп-хисап һәм башка счетлар бар. Башкарма комитет мөлкәти һәм мөлкәти булмаган шәхси хокукларны һәм бурычларны гамәлгә ашырырга, судта дәгъвачы һәм җавап бирүче булырга хокуклы, мөстәкыйль балански ия.
2.4. Башкарма комитетның юридик адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Пушкин ур., 38 й.

## 3. Башкарма комитет вәкаләтләре

1. Авыл җирлеге Башкарма комитеты:
1) планлаштыру, бюджет, финанс һәм исәпкә алу өлкәсендә:
- җирлек бюджеты проектын, җирлекнең комплексłы социаль-икътисади үсеш планнары һәм программалары проектларын төзи;
- җирлек бюджетының үтәлешен тәэмин итә, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш планнары һәм программаларының үтәлешен оештыра;
- җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш программаларының һәм планнарының үтәлеше турында отчет әзерли;

- җирлекнең икътисад һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына бирүне оештыра;

2) җирлек территориясендә муниципаль милеккә идарә, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәте белән идарә итә, муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, куллану, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

- җирлек Советы карары белән билгеләнгән очракларда, җирлек Советы килешүенә (раславына) муниципаль милекне читләштерү, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәр әзерли һәм кертә;

- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән җирлекнең икътисади һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек итү турында килешүләр төзи; җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр булдыруга ярдәм итә;

- җирлек советы билгеләгән тәртиптә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр булдыра, аларның эшчәнлек максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль учреждениеләрне һәм Предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, аларның җитәкчеләрен контракт нигезендә билгели һәм биләп торган вазыйфаларыннан азат итә;

-муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итүне һәм муниципаль йөкләмәне бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыра;

3) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- җирлекнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын, җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшли һәм тормышка ашыра, аларга карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;

- җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә;

- базарлар һәм ярминкәләр оештыра;

- ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыра һәм күмү урыннарын карап тотуны тәэмин итә;

- энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны раслый һәм тормышка ашыра, җирлек чикләрендә муниципаль торак фонды булган күпфатирлы йортларга энергетика тикшерүен оештыра, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнарда каралган башка чаралар оештыра һәм үткәрә ;

- коммуналь инфраструктура системасына тоташтыру тарифларын, коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын тоташтыруга, коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларга өстәмәләрне, кулланучылар өчен бәяләргә (тарифларга) өстәмәләрне җайга сала;

- авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә ярдәм итә һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтә, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыра;

4) мәдәният, спорт, балалар һәм яшьләр белән эшләү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү өлкәсендә:

- халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- җирлек территориясендә физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итә, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыра;

- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра;

- җирлек территориясендә законнар, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары актлары үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судта, җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хокукларын бозучы актларына карата шикаять бирә;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итә;

- муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләү һәм үткәрүне, җирлек депутатын, җирлекнең сайлау органы әгъзасын, җирлекнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирүне, җирлек чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыра һәм матди-техник яктан тәэмин итә;

- җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, җирлек Советы депутатларын, муниципаль хезмәткәрләрне һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыра, Россия Федерациясенең мәгариф турындагы законнарында һәм муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыра;

- җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр һәм пикетлар уздыруга, спорт, тамаша һәм башка массакүләм иҗтимагый чаралар үткәрүгә бәйле законнарда каралган чараларны гамәлгә ашыра;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтүне тәэмин итә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;

5) төзекләндерү өлкәсендә:

- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыюны һәм чыгаруны оештыра;

- җирлек территориясен төзекләндерү, урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту буенча эшчәнлекне оештыра);

- адреслар бирүне, адресларны үзгәртү, юкка чыгаруны, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары атамаларын бирүне, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгаруны, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыруны гамәлгә ашыра;

6) җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өлкәсендә:

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди һәм финанс чараларын исәпкә алып бара һәм тиешле файдалануны тәэмин итә;

- федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра;

- җирлек Советы карарлары нигезендә үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагында булган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалануны тәэмин итә;

7) башка вәкаләтләр:

- җирлек башлыгы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка яктан тәэмин итүне башкара;

- җирлекнең архив фондларын формалаштыруны тәэмин итә;

-җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында авыл җирлеге өчен әһәмиятле булган социаль әһәмиятле эшләрне (шул исәптән дежурлыкларны) ирекле нигездә башкаруга гражданнарны җәлеп итү турында карар кабул итә һәм аларны үткәрүне оештыра;

- федераль законнар нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;

- җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне, законнарда, әлеге Уставта каралган вәкаләтләрдән тыш, җирлек Советы карарлары белән җирлек Советы яисә җирлекнең башка җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертә.

2. Башкарма комитет җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- җирлек музейлары булдыра;

- опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнаша;

- җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни мохтариятләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга ярдәм итә;

- җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм тормышка ашыруда катнаша;

- муниципаль янгын сагы булдыра;

«Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра.

- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

- кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтә.

- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук Гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларга ярдәм күрсәтә;

- оешмалар тарафыннан федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыра;

- гражданнарга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак законнары нигезендә муниципаль торак фондының торак урыннарын бирә;

-җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын күрә.

3. Җирлекнең башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган була.

Муниципаль контроль өлкәсендә Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләренә керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) федераль законнарда, законнарда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре, мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә, җирлек башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, тикшерүләрне оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

## 4. Башкарма комитет җитәкчесе

4.1. Җирлекнең Башкарма комитетын җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - Башкарма комитет җитәкчесе) җитәкли.
4.2.Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе әлеге вазыйфага контракт буенча билгеләнүче җирле үзидарәнең вазыйфаи заты булып тора.
4.3.Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе үз вәкаләтләрен даими нигездә башкара.
4.4.Башкарма комитет Җитәкчесе, педагогик, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, эшкуарлык, шулай ук башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуксыз.
4.5.Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү конкурс нигезендә үткәрелә.
4.6. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе өчен контракт шартлары Җирлек Советы тарафыннан раслана. Федераль закон яисә Татарстан Республикасы законы белән җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнарына тапшырган очракта, контрактка Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән шартлар кертелә.
4.7. Җирлек Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына кандидатлар ия булырга тиеш:

- «Дәүләт һәм муниципаль идарә» белгечлеге буенча югары һөнәри белемгә йә «Дәүләт һәм муниципаль идарә» белгечлеге буенча өстәмә белем бирү буенча дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү учреждениесе тарафыннан бирелгән документ белән расланган кимендә 500 сәгать күләмендә югары һөнәри белемгә;
- тиешле вазыйфаи төркемнең муниципаль вазыйфаларында яисә аларга тиңләштерелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы йә белгечлек буенча кимендә биш ел эш стажына;
- җитәкче, оешма җитәкчесе урынбасарының, дәүләт органының, җирле үзидарә органының, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең вазыйфаларында кимендә өч ел идарә эшчәнлеге тәҗрибәсенә.

4.8. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм Җирлек Советы карарына ярашлы уздырыла.

4.9. Җирлек Советы тарафыннан контракт шартлары расланганнан соң, Җирлек башлыгы ике атна эчендә конкурс үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели, шулай ук контракт проекты текстын раслый.

4.10. Конкурс шартлары, аны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында белешмәләр, контракт проекты конкурс уздыру көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш.
4.11.Конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.
4.12. Җирлекнең конкурс комиссиясе әгъзалары Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.
4.13. Шәхес конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнә.
4.14. Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт Җирлек Башлыгы тарафыннан төзелә.
4.15. Аерым оештыру-боеру функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары бар, ул шулай ук Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе вакытлыча булмаганда (авыру яки отпускка бәйле рәвештә) яки үз бурычларын үти алмаганда яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның вәкаләтләрен башкара.

## 5. Башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләре

5.1.Башкару-боеру эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Башкарма комитет Җитәкчесе:
- Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге белән бердәм идарә итү принципларында җитәкчелек итә һәм җирлек башкарма комитеты вәкаләтләренең үтәлеше өчен шәхси җавап тота;

- Җирлек советы, Җирлек башлыгы, җирлекнең һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарәсенең бүтән органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә Җирлекнең Башкарма комитетын тәкъдим итә;
- Җирлек Советы каравына Җирлек бюджеты проектларын һәм аның үтәлеше турындагы хисапларны тапшыра;
- Җирлек Советы каравына Җирлек халкын комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын һәм аларның үтәлеше турындагы хисапларны тапшыра;
- Җирлек Советы раславына Башкарма комитет структурасы проектын кертә, хезмәткәрләр санының иң чик структурасы һәм хезмәткә түләү фонды билгеләгән структура нигезендә Җирлек Башкарма комитетының штат расписаниесен раслый;
- Җирлек башлыгы белән килештереп Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарын билгеләп куя һәм вазыйфасыннан азат итә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм җирлек башкарма комитетының башка хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфасыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата бүләкләү һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;
- Җирлек акчасы белән расланган бюджет нигезендә эш итә, банк учреждениеләрендә җирлекнең бюджет һәм башка счетларын ача һәм каплый;
- Җирлек башкарма комитеты тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә һәм аларның үтәлеше өчен персональ җавап тота; тиешле законнар нигезендә һәм үтәү йөзеннән тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара;
- Җирлекнең Башкарма комитеты компетенциясенә кертелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча хокукый актлар, шулай ук Җирлек Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;
- Җирлек Советына үз эшчәнлеге һәм Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге һәм нәтиҗәләре турында, шул исәптән Җирлек Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисапларны тапшыра;
- Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге турында халыкка даими мәгълүмат бирә, Җирлекнең Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга кимендә бер тапкыр гражданнарны шәхси кабул итүне гамәлгә ашыра, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;
- дәүләт һәм башка органнарда Җирлекнең мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын күрә, Җирлек Башкарма комитеты исеменнән судка гариза бирә, ышанычнамәләр бирә;
- кануннар, әлеге Устав, Җирлек Советы карарлары һәм төзелгән контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.
- мөлкәти һәм башка хокукларны һәм бурычларны гамәлгә ашырырга, судта муниципаль берәмлек исеменнән ышанычнамәсез чыгыш ясарга хокуклы.

Башкарма комитет җитәкчесе федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль берәмлек вәкиллекле органының уставында, норматив хокукый актларында билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча Башкарма комитетның карарларын, шулай ук Башкарма комитетның эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләрен чыгара

6.Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре срогы һәм вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу

6.1.Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе затны Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына билгеләп кую турында карар кабул иткән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чорына (яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эшли башлаган көнгә кадәр), әмма кимендә ике елга билгеләнә.

6.2.Җирлек Советының вәкаләтләре чоры тәмамлангач, Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе билгеләнгән тәртиптә яңа Җирлек Башкарма комитеты Җитәкчесе билгеләнгәнчегә кадәр үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәвам итә.
Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:
үлүе очрагында;
үз теләге белән отставкага китүе очрагында;
- әлеге статьяның 2 пункты нигезендә контрактны өзүе очрагында;
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфасыннан ваз кичүе орагында;
- суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу очрагында;
- суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә үлгән дип игълан ителсә;
- аңа карата судның гаепләү карары закон көченә керсә;
- даими яшәү урынына Россия Федерациясеннән читкә чыгуы очрагында;
- Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылуы, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылуы - аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;
Хәрби хезмәткә чакыру яки аны алыштыра торган альтернатив гражданлык хезмәтенә чакырылуы.
6.4. Башкарма комитет Җитәкчесе белән килешү якларның килешүе буенча яки суд тәртибендә түбәндәгеләрнең гаризасы нигезендә өзелергә мөмкин:
6.4.1. Җирлек Советы яисә Җирлек Башлыгы гаризасы - җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлештә контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә;
6.4.2. Татарстан Республикасы Президенты гаризасы - контракт шартлары федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештә бозылуга бәйле рәвештә;
6.4.3. Башкарма комитет җитәкчесе - Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары тарафыннан контракт шартлары бозылуга бәйле рәвештә.

## 7. Башкарма комитет эшчәнлеген оештыру

7.1. Башкарма комитет структурасы Башкарма комитет җитәкчесе тәкъдиме буенча Җирлек Советы тарафыннан раслана.
7.2. Җирлек Башкарма комитеты структурасына Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасары, башка вазыйфаи затлар һәм (яисә) Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары керә.
7.3. Җирлек Башкарма комитеты органнары
Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана торган нигезләмәләр нигезендә эш итәләр.
7.4. Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлегендә ярдәм күрсәтү, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне килешеп хәл итү өчен Җирлек Башкарма комитетында Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе карары белән координация, эксперт һәм башка иҗтимагый (консультатив) советлар төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән советлар Җирлек Башкарма комитеты структурасына керми. Аларда эш иҗтимагый башлангычларда тормышка ашырыла.

## 8. Хезмәт мөнәсәбәтләре

8.1. Башкарма комитетта хезмәт Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәт булып тора. Башкарма комитетта муниципаль вазыйфаларда хезмәт куючы затлар муниципаль хезмәткәрләр булып торалар.

8.2. Башкарма комитетның һәм хезмәткәрләрнең (муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль хезмәткәр булмаган техник хезмәткәрләрнең) мөнәсәбәтләре хезмәт законнары, Россия Федерациясе һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына.
8.3. Башкарма комитетның һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең һәм предприятиеләрнең җитәкчеләре арасындагы мөнәсәбәтләр хезмәт законнары, граждан законнары, әлеге Нигезләмә, алар белән хезмәт килешүләре төзелү белән җайга салына.
8.4. Башкарма комитет хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
8.5. Башкарма комитет Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган хезмәтне саклау чараларын гамәлгә ашыра һәм законнарда билгеләнгән җаваплылыкны тота.

## 9. Башкарма комитетының мөлкәт һәм финанс эшчәнлеге

9.1 Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары Җирлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән каралган.
9.2. Башкарма комитетның финанс һәм икътисадый нигезен тәшкил итә: Җирлек бюджеты, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр, башкарма комитет карамагына тапшырылган функцияләрне тәэмин итү өчен төзелгән, шулай ук идарәчелек функцияләрен башкару өчен Башкарма комитетка тапшырылган башка муниципаль мөлкәт.

## 10. Башкарма комитетны бетерү һәм үзгәртеп кору

10.1. Башкарма комитетны бетерү һәм үзгәртеп кору федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм җирле үзидарә органнарының норматив актларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла